**СОВЕТ УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Усады, ул. Советская, 41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Усад авылы, Совет ур., 41

тел./факс 8(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**25 марта 2021 г.** **№ 22**

## Советның 2019 елның 02 сентябрдәге 186 нчы номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Усад авыл җирлеге Советының 2019 елның 2 сентябрдәге 186 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәнең (Советның 07.09.2020 № 228 карары редакциясендә) 3 бүлегенең 3.3. пунктына түбәндәге эчтәлекле 17 пункт белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

«17) алкогольле, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Ф.А.Зәбиров